**СОВЕТ ТАТАРСКО - ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с., Татарский Янтык
ул. Магазинная , дом 31а
тел:/факс: 8(84378) 3-26-21
e-mail:Tyan.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422634, Татар Янтыгы авылы,
Кибет урамы, 31 а йорт
тел:/факс: 8(84378) 3-26-21
e-mail:Tyan.La@tatar.ru

==========================================================

**2023 елның 24 ноябре** **83 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлегенең Татар Янтыгы торак пунктында гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегендәге Татар Янтыгы торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлегенең Татар Янтыгы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2024 елда үзара салым салу акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Мәктәп, Казан урамнары буенча Татар Янтыгы торак пунктында су белән тәэмин итү системасын төзү, төзекләндерү, реконструкцияләү (материал сатып алу, йөк ташу, торбалар салу, шартнамә, ПСД һәм технадзор буенча эшләр өчен түләү)).

3. Әлеге карарны Татар Янтыгы авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ___________________ Н.Ш. Мифтахов
(имза) (имза расшифровкасы)

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы**
**авыл җирлеге Советы рәисе:** Н.Ш. Мифтахов
(имза) (имза расшифровкасы)